КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 855

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 гыйнвар, 55 нче карары белән расланган Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З.Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен яңадан җиһазландыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 гыйнвар, 55 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июнь, 614 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибенә, 5 пункттагы «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәре җиткерелгәннән соң 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм

расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин